1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 10 / 2024

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



ШӘҺӘР *авыл арасы* ***алтын бәясе***

*психотип* ***буенча киенү*** ЭТИКЕТ

*дөрес туклану* ПАШТЕТ

## *Флора Галиева:*

***«Хатын-кыз – чәчәк гөлләмәсе ул!»***

podpiska.pochta.ru



# МӘХӘББӘТ ТЕЛЕН БЕЛӘСЕЗМЕ?

**Ир-ат белән хатын-кызны бер-берсенә бәйли торган күзгә күренмәс җепләр, мөгаен, дөньядагы иң нечкә җепләрдер. Аларны кайчак аз гына саксыз кагылу, бер саксыз караш, бер ялгыш сүз дә өзәргә мөмкин. Башка беркайчан бәйләнмәслек итеп өзәргә... Ике арадагы җылы мөнәсәбәтләрне ничек сакларга, дөресрәге, язмышның бер сынавы да сындырмаслык итеп баштан ук ничек төзергә соң? Бу юлда нинди хаталар ясамаска? Рамил хәзрәт ЮНЫС белән шушы хакта сөйләшәбез.**

**Гаилә тормышына әзер булырга кирәк дибез, ә бу әзерлекне яшьләр кайчан һәм ничек башларга тиеш?**

– Шундый тәҗрибәм бар: никах укырга сорап мөрәҗәгать иткән парларны бер ай алдан үземә чакырам. Ике якның да әти-әниләре белән бергә килсәгез әйбәтрәк, дим. Барыбыз бергә утырып сөйләшәбез. Бик үтемле очрашу була ул, аны башка хәзрәтләргә дә кулланырга кирәктер. Мин анда яшьләргә гаилә тормышының асылын аңлатырга тырышам. Булачак киленгә болай дим: «Китаплардан укып, кинолардан карап, минем ирем шундый-шундый булачак, дип хыяллангансың. Инде менә хәзер ул янында утыра, монысы – Аллаһтан бирелгәне. Бу инде виртуаль түгел, реаль кеше. Хәзер моның белән яшәргә кирәк».

Һәммә кешенең яхшы ягы да, зәгыйфь ягы да бар. Никахланганга кадәр без барыбыз да бер-беребезгә бары тик яхшы ягыбызны гына күрсәтергә тырышабыз. Син дә фәрештә, ул да аккош кебек... Очрашып йөрисез, бөтен кеше дә сезгә карап соклана. Ә аннары, никах укылгач, туйлар узгач, көтелмәгән хәлләр башлана... Бер җитәкче миңа: «Хәзрәт, мин менә кешеләрне эшкә алам. Каяндыр алып килгән характеристикаларын укып та тормыйча, шунда ук өстәл астына тыгып куям. Кешенең кем икәнлеген ситуациядә генә күреп була. Шуңа күрә күпләр миндә беренче ситуациягә кадәр генә эшли. Бер ай, ике ай, өч ай уза... Ниндидер бер ситуация килеп чыкмый калмый һәм шул вакыт кеше үзен ничек тота, шуңа карыйм: эгоист түгел икән, ул миндә эшләп кала», – дип сөйләгән иде.

Мин дә кавышырга җыенган парларга шулай дим. «Сезнең тормышта да ниндидер ситуацияләр тумый калмаячак һәм шунда зәгыйфь ягыгыз ачыла башлаячак. Икегезнеке дә! Бу, һичшиксез, шулай булачак! Моңа әзер булыгыз», – дим.

Яшьләргә менә болар хакында беркем сөйләми, әйтми бит. «Инде шундый бер хәл булды дип күз алдына китерик. Әлбәттә, тетрәнеп каласыз. Егет белән кыз булып йөргәндә, син аның бары әйбәт ягын гына күрә идең бит, ә монда холкының моңарчы белмәгән яңа ягы ачыла... Һәм ул сиңа бөтенләй ошамый! «Мин аның моңарчы үзем белгән якларын гына яратам», – диясегез килә сезнең. Әйе, ул яклары сезгә ошый, тик бит менә монысы да бар, анысын нишләтәбез?» – дим. Яраткан очракта тулысынча кабул итәсең. Йә сабыр итәсең, йә әкренләп үзгәртәсең.

Беренче сынаудан ук икең ике якка борылып китмәс өчен боларны алдан ук белеп тору кирәк.

**Бүген аерылышуларның күп булуының бер сәбәбе – яшьләрнең гашыйк булу белән чын мәхәббәтне, чын яратуны аермавы, ашыгып гаилә корулары аркасында түгелме икән?**

– Күпләр шулай уйлый, чынлыкта исә аерылышуларның төп сәбәбе бөтенләй башка нәрсәдә. Статистика буенча, Россиядә аерылышуларның иң беренче сәбәбе ир-атның эчүе дә, торырга урын булмау да, акча җитмәү дә түгел, ә... өлкәннәрнең яшьләр тормышына кысылуы, катышуы тора. Никах мәҗлесләрендә яшьләргә гел: «Ике яктан да әти-әниегезне хөрмәт итегез», – дим. Һәм шуннан соң ук өлкәннәргә: «Ә сез бүгеннән балаларыгызны үзегездән җибәрегез», – дип мөрәҗәгать итәм. Тик, кызганыч, күп әти-әни монь эшләми шул. Психолог буларак, бу шунда ук минем күзгә ташлана. Әгәр егетнең әнисе, ягъни кайнана улын үзеннән җибәрә алмый икән, ул яшьләр тормышы белән яши башлый. Ике көннең берендә ул һаман аларда: киленне дә өйрәтә, улын да. Аны алмагыз, моны алыгыз, анда бармагыз, монда барыгыз... Әгәр шушы күренеш күзәтелә икән, 100 процент гарантия белән әйтергә була, димәк, бу ханымның ире белән икесенең арасында аңлашылмаучылык бар. Тормышларының кайсыдыр моментында алар ниндидер җитди проблема белән очрашканнар, әмма аерылышмаганнар, бергә яшәп калганнар. Мондый гаиләләр бездә 70–80 процент чамасы... Һәм шушы хәлдән соң бу ханым үзенең бөтен тормышын, бөтен мәхәббәтен улына багышлаган. Ире бармы – бар гына булган. Ике сүзнең берендә: «Минем Артурик», – дип кабатлый ул. Ә Хәнәфи абый белән бергә бер түбә астында яшиләр, бергә туйга гына килеп утырганнар менә. Хатын-кызга исә бөтен тормышын ир-атка багышлау кирәк, бу очракта ир-атны улы алыштырган. Малай кеше инде үскән, 24 яшенә җиткән һәм көннәрдән бер көнне: «Мин өйләнәм!» – дип кайтып әйткән... Ана кеше өчен бу – фаҗига! Тик нишләсен, каршы да төшә алмый – улы өйләнәм, ди бит. Карый киленгә: болай ярый да кебек тә бит...

## Элек гаиләләр бәхетлерәк булган: алар бер-берсенә кирәклекне тойган.

Көлмәгез, мин консультациядә дә нәкъ шулай сөйлим, аңласыннар дип. Чын тормыш бит шундый... Алга таба сценарий болай дәвам итә. Кайнана озаклamый чәчәнә ябыша: юха елан булып чыкты бу килен – малаемның башын әйләндерә! Күлмәген дә үтүкләмәгән! Кайткан җиренә ашы да әзер түгел! Идәнне дә Артурик юа!

Беренчедән, әни кеше Артурикны ир кеше ничек булырга тиеш дип тәрбияләмәгән. Чөнки улы әтидән читләштерелгән, ул – әни малае. Артур үзенең чикләрен билгели белми – хатын-кыз фикеренә бик нык бәйле. Һәрвакыт хатын-кызның – әнисенең сүзен тыңлап өйрәнгән. Шуңа күрә үз гаиләсендә дә хатын сүзен тыңлый. Әмма горизонтта әни кеше күренсә, ике ут арасында кала – кем сүзенә күбрәк колак салырга белми аптырый... Аннан инде яшь гаиләнең таркалуына да ерак калмый.

Гаиләдә шуңа охшаш проблема тугач, ирле-хатынлы консультациягә киләләр. Хатыны кайнанадан зарлана: алай дип әйтә, болай дип әйтә, ди... Ире нишләргә белми утыра. Тыңлыйм да: «Психологиядә шундый бер ысул бар, – дим аларга. – «Әнидән аерылу» дип атала ул. Мин аны үзем «Камал театры» дип атыйм. Иртәгә икәү әниегез янына барасыз: хәлләрен белешәсез, утырып бергә чәй эчәсез. Аннары әйтәсез: «Әни, без сине бик яратабыз, әмма моннан соң сиңа сирәгрәк килербез инде. Обойны да үзебез алырбыз, дисез». Шуннан соң, беләсезме, нәрсә була? Уф-ф, дип, әни кеше йөрәгенә ябыша. «Бөтенләй килмәсәгез дә сүзем юк! Әйе, хәзер бит синең хатының бар! Бар, хатыныңны ал да чыгып кит, шуның белән яшә!» – ди. Бу спектакльне ахырына кадәр тыныч кына карап утырырга кирәк. Ул тәмамлангач, тагын җитди сүзгә күчәргә һәм: «Әни, безнең үз тормышыбыз, аерылышырга җыенмыйбыз... Сине исә хөрмәт итәбез, яратабыз. Әйдә, шулай килешик...» – дияргә кирәк.

Күптән түгел бер ханым шалтырата: 38 яшьлек улын миңа консультациягә алып килмәкче була икән. «Үзенең теләге бармы?» – дип сорыйм. «Юк», – ди. «Ә нәрсә булды аңа?» – дим. «Тезенә операция ясатты, аягы һаман төзәлми, чатанлап йөри. Сезнең сүзне тыңлап кына кердем пычак астына, дип әйтә», – ди.

podpiska.pochta.ru

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Кичен яшьләр күңел ачкан үзәкләрдә чыгыш ясаучы кавер-төркем солисты ул, ә көндез… көндез үз дөньясы – фольклорга чума. Самара татарларының халык авыз иҗаты турында сәгатьләр буе сөйләргә мөмкин. Күзләрдә очкын яна, йөрәге сикерә, үзеннән гасырларны колачларлык энергия бөркелә бу мәлдә. Бер гасырга гына сыймый кебек ул. Шуңа да үткәннәрдә йөреп, шул тарихны барлый, туплаганын киләсе буынга тапшыра. «Мин шуның өчен туган, ахрысы. Җирдәге вәкаләтем шул. Әби-бабаларның энергиясен тоям үземдә. Тикмәгә генә нәселебезнең иң хөрмәтле һәм көчле хатын-кызы исемен кушмаганнар миңа», – ди Самарадагы «Заман» балалар фольклор ансамбле җитәкчесе Вәсимә ФӘРДИЕВА.



# ВӘСИМӘ ҺӘМ ЗАМАН

Фото: Тимур Сафин

Сәхнәдә – балалар. Кемнеңдер кулында самавыр торбасы, кайсыдыр кер тактасы тоткан, өченчеләрендә – агач кашыклар. Араларында скрипкада уйнаучы да бар. Костюмнары да без сәхнәләрдән күреп гадәтләнгән түгел, күбрәк көнкүреш тормыш белән бәйле кебек. Менә алар «Сербиянка» җырын башкара. Ул заманлаштырылмаган, хәтта диалектларны да саклаганнар. Киләчәк буын әби-бабаларының рухи байлыкларын популярлаштыра. Бу – Вәсимәнең күптәнге хыялы. Ниһаять!

Камышлы районы Балыклы авылында туган Вәсимәнең әбисе мулла кызы була. Ул төпчек оныгына совет дәүләте кулак исеме таккан әтисе, төрле кыйтгаларга чәчелгән туганнары, репрессиягә эләгеп, ун ел буе төрмәдә утырып кайткан апасы Вәсимә турында сөйли. Ләкин кечкенә кызчык боларның барысын да аңлап бетерми, балалыгы белән әбисенең хатирәләренең кыйммәтен күрми, әмма шулай да колагына кереп кала. Ул кечкенәдән белеп үсә: аңа исемне шул Вәсимә апага хөрмәт йөзеннән биргәннәр. Төрмәдән кайтып, гаилә кора алмаган кыз сеңлесенең балаларын тәрбияләргә ярдәм итә. Икенче әни була ул аларга. Бик чибәр булган, матур итеп җырлаган. Бу хакта Вәсимәгә әтисе дә сөйли. Мәктәптә укыганда нәсел-нәсәп турында инша язарга бирәләр. Әтисе белән бергә башкаралар бу эшне. «Ул инша миңа бик нык тәэсир итте. Мин әтигә йөз төрле сорау бирдем. Туганнарыбызны табасым килде», – ди. Узган заманнар белән кызыксынуы әнә шуннан башлана да бугай инде. Җиде буыны язылган шәҗәрәне ачып сала да нәсел агачыннан чыккан ботаклардан туганнарын эзли башлый. Шул вакытта ул төш тә күрә. «Син туганнарны җыярга тиеш!» – дип әйтүче әнә шул Вәсимә әбисе булмады да микән әле? Казан, Мәскәү, Петербург, Үзбәкстан, АКШта көн итеп яткан туганнарын җыеп, мессенджерда уртак төркемнәрен төзеп, аралашып яши башлагач кына җаны тынычлана.

Вәсимә апасының моңы аңа да күчкәнме, җырларга ярата кыз. Мәктәптә физкультура укытучысы булып эшләгән әнисе дә, җитәкче урыннарда эшләгән әтисе дә җырламый. Апасы белән абыйсы да әнисе кебек спортка мөкиббән. Ярышлардан кайтып кермиләр, ә менә Вәсимә җырларга ярата. Әнисе кызының сәләтен тагын да үстерер өчен 160 чакрым ераклыктагы Кинель-Черкасскига, юлда очраган машиналарга утыра-утыра, сигез ел буе вокал дәресләренә йөртә. Вәсимә моның өчен әнисенә бик рәхмәтле. Мәктәпне тәмамлауга Самарага китеп, мәдәният институтының соло һәм халык җыры белгечлеге бүлегенә укырга керә. Менә шунда ул икенче бер серле дөнья – фольклор белән таныша. Рус фольклорын өйрәнер өчен экспедицияләргә чыгып китә алар. «Анда бер тапкыр барып кайтуга фольклор белән «авырый» башлыйсың. Югыйсә бернинди уңайлылыгы булмаган җирләрдә куна идек: спортзал, мәктәп идәннәре… Ә менә әби-бабайлар белән сөйләшкәндә бөтен дөньяңны онытасың. Алар – аяклы хәзинә. Үзләрендә күпме байлык-истәлекләр саклыйлар», – ди Вәсимә. Укытучысы Елена Саенко үз халкының иҗаты белән кызыксынырга этәргеч бирә аңа. «Вәсимә, син үзеңнекен кара, үзеңнекен эзлә», – дип киңәш итә. Рус традицион мәдәнияте үзәге белән экспедицияләргә чыккан саен юллары татар авылыннан узса, анда кереп әби-бабайлар белән сөйләшеп – «байлык туплап» чыгарга иярләшеп китә. Фольклорны өйрәнгән саен өйрәнәсе килә аның. Өлкәдә татар халык авыз иҗатын җыючылар да юк икән бит. Нигә әле мин үз җирле халкымның фольклорын күтәрмәскә тиеш? «Мин булмасам – кем?» дигән уй шул вакытта кереп утыра аңа. Әмма ул бу хыялына урау юллар белән килә…

«Мин булмасам – кем?» дигән уй шул вакытта кереп утыра аңа. Әмма ул бу хыялына урау юллар белән килә…

Институтны тәмамлагач, Самараның «Яктылык» татар мәктәбендә эшли. Балалар белән төрле концертлар оештыра, өлкәдә үткәрелгән бик күп чараларда, бәйгеләрдә катнашалар. Шул вакытта «Идел» халык ансамбле җитәкчесе гармунчы Мидхәт Әминов белән таныша. Аннан соң аны язмыш җилләре Ялтага алып китә. Анда Ренат Ибраһимов исемендәге халыкара музыка мәктәбендә педагог булып эшли. Бераздан Мәскәүгә күченә. Бәлки, шунда төпләнеп калып, бөтенләй башка тормыш белән яшәп тә киткән булыр иде, әмма Мәскәүдә авырып, операция өстәленә ята. Уңышсыз чыгып, операцияне кат-кат ясыйлар. Бер аягы йөрмәскә әйләнә. Авырлык килсә, кеше әти-әни янына кайтып егыла. Вәсимә дә авылына кайта. Аягына басар өчен тернәкләндерү курслары уза. «Мин дөрес яшәмим, ахрысы. Үземнән соң нәрсә калдырам?» дигән уйлар шул вакытта килә башлый аңа. Тормышындагы кискен үзгәреш тә шушында башлана бугай инде. Моңа кадәр үзен Василиса дип таныштыра торган була. Исеме истәлекле булса да, аннан ояла, кабул итә алмый. Шушы чорда ул үз исеменең бик сирәк, затлы татар исеме булуын аңлый. Дуслары да аның иске яңа исемен кабул итә. Хәзер аңа барысы да Вәсимә дип эндәшә. Тернәкләндерү курсларын тәмамлаганнан соң аны Самарадагы «The Players» кавер-төркемгә җырларга чакыралар.

Менә шулай, кабат шәһәргә күченә. Үзе генә түгел, хыялы белән. Фольклор ансамбле оештырачак ул. Үзе белгәннәрне балаларга өйрәтәчәк. Киңәшергә Мидхәт янына килә. Халык мәдәниятен саклап калу өчен бөтен җаны-тәне белән янып йөргән үзешчән артист бик шатланып фатихасын бирә. Әле ярдәм дә итәчәк. Аның кебек балалар белән мәш килеп гармунда уйнап йөрүчеләр юк ул хәзер Самарада. «Идел» халык ансамбле каршында «Заман» балалар фольклор ансамбле төзергә ниятлиләр. Төркемгә исемне үзе бирә Вәсимә. Заман – чор, дәвер ул. Балалар белән бергәләп чорлар колачлаячак алар! Өлкәдә чыгып килгән татар газетасына балалар ансамбле оештыру турында белдерү бирүгә, улын-кызын җитәкләп әниләр килә башлый. Күбесенең баласы туган телен начар белә. Әниләр әнә шулай фольклор аркылы ул-кызларында милли аң уятырга тели. Аннан соң Вәсимәнең балалар белән ничек эшләве турында хәбәрдар булалар. Елмаеп-көлеп кенә сөйләшсә дә, укытучы апалары таләпчән – куйган максатына ирешми калмый. Вәсимә балаларга җырлар өйрәтә башлый. Бик авырдан өйрәнсәләр дә, балаларга ошый. Уен рәвешендә барган дәресләргә яратып йөриләр. Хәзер ансамбльдә барысы 15 бала шөгыльләнә. Иң кечкенәсенә – 5 яшь. Апасы йөри башлагач, кызыгып, сеңлесе йә энесе ияреп килгәннәр дә бар. Берсен дә кире бормый Вәсимә. «Аларны энҗе бөртеге кебек җыям. Бәлки, киләчәктә мине искә дә алмаслар, әмма күңелләрендә мин салган орлык кайчан да булса бер шытмый калмас», – ди ул. Ансамбльгә әле бер елдан артык кына булса да, уңышлары да бар инде. Ел эчендә биш җыр өйрәнәләр. Кайда чыгыш ясарга чакыралар, шунда баралар. Үзләренә дә кызык. «Бер айда ун җирдә чыгыш ясаган да булды», – дип горурлана Вәсимә. Балалар өчен генә түгел, фольклорны популярлаштыруга да сөенә. «Татарстан–Яңа гасыр» каналы



Фото: Анна Арахамия

# АПА



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

**– Укудан ашыгып кайтып, ишекне ачып керәсең, ә өйдә беркем юк… Колакны ярырдай тынлык кына… Шулай итеп өчәү генә калдык… Без аның тормышындагы иң авыр көннәре турында сөйләшәбез, әмма Фәрзәнәнең күзләрендә яшь юк. («Мин сирәк елыйм шул… Югыйсә ешрак еларга, бушанырга кирәк. Көчле булырга кирәк, дип, үземне бик нык кысаларга кертканмен. Хәзер менә психологка йөрим, чөнки барысын да эчемә җыеп барырга ярамаганын инде аңлыйм», – ди ул миңа соңрак.) Алар гаиләсе Самара татарларына гына түгел, бөтен татар дөньясына таныш иде дисәм дә ялгышмам. Фәрхәт Мәхмүтов – Самара өлкә татар милли-мәдәни автономиясенең һәм өлкә «Туган тел» татар җәмгыятенең башкарма директоры, Альбина Мәхмүтова – «Ялкынлы яшьлек» җыр, бию һәм шигърият ансамбленең җитәкчесе. Гаиләдә өч бала үсеп килә: Фәрзәнә, Самат, Таһир. Өчесе дә татарча сөйләшә. Фәрзәнә инде әти-әнисе кебек үк татар оешмалары эшендә катнаша: шәһәр күләмендәге Сабантуйларны, кичәләрне алып бара, татарча җырлый.**
**Әйе, барысы да әйбәт була.**

– Гап-гади көн иде ул. 2019 елның 27 мае, ураза вакыты. Самат өйдә калды, без иртән дүртәү җыенып чыгып киттек. Тик урам башына җитүгә, әти: «Әллә нәрсә булды әле», – дип, машинаны туктатты. Әни миңа Таһирны балалар бакчасына илтеп килергә кушты, үзе «Ашыгыч ярдәм» чакыртып калды. Кире килсәм, әни елап басып тора, әти исә әле аңында булса да, хәле бик начар. Ерак түгел даруханә бар иде – даруга чаптым. 5 минут эчендә әйләнеп тә килдем. Әтине инде «Ашыгыч ярдәм» машинасы эченә кертеп салганнар, нидер эшлиләр… Бер гомер кадәр вакыт узды. Аннан, табиб яныбызга чыкты да: «Коткара алмадык…» – диде… Әтигә нибары 47 яшь иде…

18 яше яңа тулган Фәрзәнә ул чакта әнисенең төп таянычына, төп терәгенә әйләнә. Берсендә документлар ясату өчен пенсия фондына килә: андагы хезмәткәрләрнең үзеннән нинди кәгазьләр соравын аңламагач, ирексездән күзеннән яшь ага башлый. Үзенең кинәт олыгайганын шул минутта аңлый ул. Әнисенә көтмәгәндә килгән бу югалтуның зурлыгын аңлау исә авыр түгел. Кулында өч бала, иң кечесенә нибары 3 яшь, төзелеп бетмәгән йорт…

Фәрхәт белән Альбина шәһәрдә узган милли чараларның берсендә танышалар. Бу вакыт Самарадагы татар яшьләре оешмасын җитәкләгән егеткә озакламый бер төркем яшьләрне Казанга алып барырга туры килә. Шул ук автобуста Альбина да алар белән бара: Татарстанда узачак бер җыр конкурсында катнашырга җыена икән. Бәйгене оештыручылар кызны: «Җырчылар бик күп, бәлки бии беләсездер?» – дип каршылыйлар. Альбина шунда ук Айгөл Бариеваның «Чабата» җырына бию куя һәм… беренче урынны ала! Шушы җиңү шатлыгы араларны тагын да якынайта. Әмма, беренче чиратта, күңелләр якынлыгы, фикерләр, карашлар уртаклыгы аларны бер-берсенә бәйли. (Самара педагогика көллиятендә музыка укытучысы булып та эшләгән Альбина Мәхмүтова ире кебек милли оешмалар җитәкләми, әлбәттә, әмма аның дәресләрендә хәтта рус балалары да татарча җырлый.)

Фәрхәтсез калу – канатлар сыну белән бер булгандыр аңа.

2022 елның сентябрендә авырый башлый. Диагнозны бик тиз куялар: яман шеш… Операцияне октябрь башына билгелиләр. Ә 22 октябрьдә ансамбльнең концерты булырга тиеш, шуңа күрә Альбина хастаханәгә соңрак керергә хәл итә. Ул концертны кызы Фәрзәнә алып бара.

– Концерттан соң ике көн узуга, әни больницага кереп ятты. Башта Таһирны авылга кайтарып куйды әле. Ә Саматны бер атнага Казанга, «Татар балалар лидеры мәктәбе»нә җибәрдек. Әнине онкология клиникасының ул яткан бүлегенә кадәр үзем озаттым. Ковидтан соң, кертмиләр – бөтен җирдә карантин… Операциядән соң ул өч көн элемтәгә чыкмады. Төннәрен куркып-куркып ояна идем. Наркоздан соң хәле булмаган, шуңа шалтырата алмаган икән… Ике ай ятты ул больницада. Янына кертмәделәр, гел телефон аша аралаштык. Үзем чәчкәләр яраткач, кәефе күтәрелсен дип, аңа да илттем. Аяк өстендә, йөрим, дия иде. Шунда яткан килеш ансамбльне яңа концертка әзерли башлады. 24 декабрь көнне булырга тиеш иде ул, концертка әни үзе дә чыгарга өметләнде.

Бер көнне таныш медсестралар мине аның янына уздырдылар. Ниһаять, ике айга беренче тапкыр күрештек! Ябыккан, әлбәттә, әмма яныма үзе чыкты, колакларында наушник – ниндидер музыка тыңлап яткан. Шул вакыт әни: «Болар синдә торсын әле», – дип, бөтен документларны миңа тоттырды. Киткәндә аңа борылып карадым һәм нигәдер: «Бу безнең соңгы очрашу булмаса ярар иде…» – дип уйладым…

Кайтып җитүгә, «мин өйдә» дип яздым, тик ул инде җавап бирмәде. Мин китеп ике сәгать үтүгә, хәле начарланган – реанимациягә салганнар.

Бу хәбәр шунда ук Самара татарлары арасында таралды. Өлкәнең иң зур онкология үзәге бит – татарлар бик күп эшли анда: шәфкать туташлары башка бүлекләрдән килеп, әнинең хәлен белеп, булышып, юындырып йөрделәр. «Әни, бөтен Самара синең белән, бөтенебез сине уйлый! Безнең барысы да яхшы, борчылма!» – дип хат яздым. Тапшырырмын, дип, бүлек мөдире аны үзе алып калды.

Иртән шалтыратып хәлен белешәм, көндез реанимация бүлегенә үзем килеп китәм, кичкә тагын шалтыратам. Бөтен кешегә әйтеп куйдым: «Әнине борчымагыз», – дидем, чөнки аңа сөйләшү авыр икәнен, телефон тотарга да хәле булмавын белә идем.

Табиблар мине җәлләгәндер, күрәсең, әниең инде дүшәмбедән бирле комада дип берсе дә әйтмәде. Ул әлегә аңында түгел, диделәр. Чәршәмбе барсам, әни урынында юк! Операция ясыйлар, диләр. Туганнар белән мулланы алып килеп укытырга дип уйладык. Иртәгә хәзрәтне алып килсәк ярыймы, кертерсезме икән, дип сорадык. Шәфкать туташы чыкты да: «Бүген алып килә аласызмы?» – диде…

Аллаһы Тәгаләдән әнинең терелүен сорап, бөтен Самара татарлары белән 4444 тапкыр укыла торган «Саләти Нәрия» догасын укый башладык. Шуннан соң авыруның хәле йә җиңеләя, йә ул китә, диделәр. Җомга көнне без аны тәмамладык. Шимбә көнне уянуга, гадәттәгечә, реанимациягә шалтыраттым. Озак кына җавап бирмәделәр. Аннан берәү алды да: «Ә сез аның кеме буласыз?» – дип сорады. Башка вакыт мондый сорау бирмиләр иде. Бөтен бүлек әнинең өч баласы барлыгын, безнең өйдә үзебез генә икәнне белә. Шуннан соң ул телефон трубкасын өстәлгә куйды да кемгәдер: «Сез аның туганнарына хәбәр итмәдегезмени әле?» – диде.

Дөньяда энекәшләрсез – үзем генә калсам, күпкә авыррак булыр иде.





pressa.pochta.ru

# Креветкалы спринг-ролл



Спринг-ролл – япон, сингапур, индонезиялеләр кухнясы традицияләрен чагылдыручы ризык. Тәм һәм файданың тәңгәллек үрнәге ул, чөнки анда аксым да, клетчатка да, углеводлар да бар. Көндезге һәм кичке ашка да, капкалап алу өчен дә менә дигән вариант санала. Ә иң мөһиме: ул шулкадәр тиз һәм җиңел әзерләнә.

Фото: ru.freepik.com

Спринг-роллда төп ингредиент – дөге кәгазе, ә калганнары төрлечә була ала.

**Спринг-роллның корылышы**

Аксым (креветка, лосось, тавык түше, криль ите) + нечкә итеп саламлап туралган яки корея угычыннан уылган теләсә кайсы яшелчә + соус.

Без исә спринг-роллны креветка белән әзерләү ысулын тәкъдим итәбез. Моның өчен эре креветкалар яхшырак. Аларны майлы табада сарымсак белән бергә һәр ике ягын да кыздырып алабыз.

■ Яшелчәләрне турап яки угычтан уып, алдан ук әзерләп куябыз. Без кыяр, кишер, авокадо, салат яфрагы алдык.

■ Зуррак савытка су салып, дөге кәгазен чылатабыз. Дөге кәгазен суда озак тотмаска кирәк, өч-биш секунд җитә.

■ Кәгазь уртасына өч креветка куябыз, әзерләнгән яшелчәләрне һәм берәр төрле соус өстибез.

Без исә эремчекле соус кулландык. Соуслар төрлечә булырга мөмкин.

### СОЯ СОУСЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘҮ ӨЧЕН

*Кирәк*

■ 2 аш кашыгы соя соусы;
■ 1 чәй кашыгы бал;
■ 2 аш кашыгы көнҗет урбече (кунжутный урбеч);
■ ярты чәй кашыгы уылган имбир;
■ 1 тырнак сарымсак;
■ сыеклап җибәрер өчен су;

Сарымсакны уып, имбир һәм калган ингредиентлар белән катнаштырабыз. Кирәк булса, аз гына су кушабыз.

### АРАХИС ПАСТАСЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘҮ ӨЧЕН

*Кирәк*

■ 1/3 стакан арахис пастасы;
■ 2 аш кашыгы лимон яки лайм суты;
■ 3 аш кашыгы бал яки өрәңге ширбәте (кленовый сироп);
■ 1 аш кашыгы алма серкәсе;
■ 2 аш кашыгы соя соусы;
■ 1 чәй кашыгы имбир;
■ 1 тырнак сарымсак;
■ сыеклап җибәрер өчен су.

Барлык ингредиентларны блендерда ваклыйбыз. Кирәк булса, су белән сыеклыйбыз.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

# ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА БАСЫЛГАН ЯҢА КИТАПЛАР




**«БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ»** сериясе. Балалар өчен уку китаплары

Укучыларыбызның күпсанлы сораулары буенча, Татарстан китап нәшрияты «Бергәләп укыйбыз» сериясендә төрле җанрларны үз эченә туплаган рәсемле уку китаплары бастырып чыгарды. «Беренче адым», «Беренче рәхмәт», «Беренче көн» дип аталган әлеге җыентыклар – тәҗрибәле методист, гомерен мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүгә багышлаган Кафия Закирова төзегән уку китаплары. «Беренче адым» – 3 яшькә кадәрге балалар өчен. Бу китапта сабыйлар күңеленә якын һәм аңлаешлы әкиятләр, хикәяләр, баланың телен ачып, сөйләмен баетуда, зиһенен үстерүдә тәэсирле тәрбия чарасы булырлык әсәрләр урын алды.

3–5 яшьлек балалар өчен нәшер ителгән «Беренче рәхмәт» китабында халык авыз иҗатының бала күңелендә калырлык кыска үрнәкләре, классиклардан алып яңа гына әдәбият мәйданына килгән авторларыбыз иҗаты, рус һәм европа әдәбияты үрнәкләре дә тәкъдим ителә.

«Бергәләп укыйбыз» сериясендәге өченче китап – 5–7 яшьлек балаларга адресланган «Беренче көн» җыентыгы. Алдагылардан аермалы буларак, бу китап мәктәпкәчә яшьтәге оешмалар өчен белем бирү стандартларына муафыйк итеп, төрле темаларга бүленгән. Табигать кочагында, туган йорт, гаилә, хезмәт, һөнәрләр, белем, мәктәп һәм башка темаларга әсәрләр тәкъдим ителә. Зиһенгә, хәрәкәткә корылган уеннар да бар. Китапның тагын бер үзенчәлеге – укыганга нәтиҗә ясап кую өчен, мәкальләр һәм әйтемнәр дә бирелә.

*Мөхәррире – Айсылу Галиева.*
*Рәссамнары – Миләүшә Вәҗиева, Айсылу Гарипова.*

Рифат СӘЛАХ әзерләде.

# Йолдызнамә: март

***Кучкар.*** Һәртөрле яңа башлангычлар өчен яхшы ай. Үзегездә моның кадәр көч булуын әлегәчә, бәлки, белмәгәнсездер дә. Ул көчләрне дөрес юнәлешкә борсагыз, уңышның койрыгыннан эләктердем, диегез.

***Үгезбозау.*** Тормышта үз урыныгызны саклап калу өчен кыюлык таләп ителә. Җиңүне максат итеп куйсагыз, уңышка ирешерсез. Юк-барга энергиягезне сарыф итмәгез. Үзегезне кулда тотарга туры килер.

***Игезәкләр.*** Үзегездә моңарчы булмаган азарт тоярсыз. Әле кайчан гына буй җитмәстәй тоелган хыялыгызга сез хәзер бик якын. Тырышыгыз – алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачыла, бик тә перспективалы чор.

***Кысла.*** Иң мөһиме – тоткан юлыгыздан тайпылмагыз. Яңа эшкә алынмый торуыгыз хәерлерәк. Максатчан Кыслаларга үз дигәннәренә ирешү өчен яшы җай чыгар – көтмәгән җирдән ярдәм булыр.

***Арыслан.*** Үтә дә керемле ай. Түккән көчегезнең әҗерен күрерсез – уңышларыгыз икегә тапкырланачак. Бу айда башкарган эшләр киләчәккә зур кертем булыр, мөмкинлектән файдаланып калыгыз, ялкауланмагыз. Яңалыклардан куркырга кирәкми.

***Сөмбелә.*** Зурракка өметләнүдән кыенсынмагыз – язмыштан никадәр күбрәк сорасагыз, шулкадәр күбрәк бирер. Бу – тормышның һәр өлкәсенә кагыла. Үзегезне лидер ролендә сынап карарга туры килер. Инициативаны кулыгыздан ычкындырмагыз.

***Бизмән.*** Уңышның ачкычы – имидж һәм виртуоз стратегия. Канәгатьсезлегегезне бик нык яшерергә, ә менә башкаларны инандыру талантыгызны, киресенчә, тагын да ныграк чарларга туры килер.

***Чаян.*** Ашыгыч карарлар кабул итү, инициатива күрсәтү, ачыктан-ачык көрәш өчен башка вакытны сайлагыз. Бераз гына күзәтүче ролен башкарсагыз, отарсыз. Эшлекле активлык өчен бигүк кулай вакыт түгел.

***Укчы.*** Тормыш аренасында сез – гладиатор. Бу ай – яңа тәкъдимнәр, кызыклы идеяләр белән истәлекле булыр. Яңа белемнәр алу, яңа кешеләр белән элемтәләр урнаштыру өчен уңышлы чор.

***Кәҗәмөгез.*** Уйлап эш итүче Кәҗәмөгезләргә тормыш ритмы чамадан тыш тиз, ә үз эшләре акрын барган кебек тоелыр. Борчылмагыз, ыгы-зыгылы яңалыклар локомотивы сезне урап узса да, берни югалтмыйсыз. Үзегезне күрсәтү өчен яхшы форсат килеп чыгар.

***Сукояр.*** Бу айның девизы – тимерне кызуында сук! Күптәнге мәсьәләләр җиңел хәл ителәчәк. Үткәндәге үпкәләрне онытып, барысын да өр-яңадан башлар өчен менә дигән вакыт.

***Балык.*** Үзегезгә, шәхси тормышыгызны көйләүгә күбрәк игътибар бирегез. Эшкә иҗади яктан карасагыз, зуррак уңышларга ирешерсез. Гомумән, күп өлкәдә уңыш елмаячак. 10 мартта тулы ай Балыкларда була. Бу көнне теләкләр теләп калырга кирәк.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

podpiska.pochta.ru




# Фарсы ашы «Э джо»

Казанда яшәүче Гөлназ һәм Алмаз НУРМИЕВлар гаиләсендә самбо буенча чемпионнар үсә. 17 яшьлек уллары Аяз спортның бу төре белән әле мәктәпкә кергәнче үк шөгыльләнә башлаган. Бүген ул яшүсмерләр арасында Татарстан чемпионы. 8 яшьлек Анур белән 6 яшьлек Нурсолтан да абыйлары кебек самбо буенча чемпион булырга әзерләнә.

– Ике яктан да бабаларыбыз Сабантуй батырлары. Малайлар хезмәт һәм спорт белән үсәргә, киләчәктә үз гаиләләрен яклый алырга тиеш, дип саныйбыз. Шуңа да аларны самбога бирдек, – ди әтиләре Алмаз. Аның балачагы Арча районы Кылачы авылында, әби-бабасы янында узган. «Авыл – минем өчен чып-чын тормыш мәктәбе булды», – ди ул.

Гөлназның нәсел тамырлары исә Чистай районы Яуширмә авылыннан. «Минем дә каникулларым дәү әнием Зәйтүнә янында узды. Хатын-кызлар башкарырга тиешле барлык эшләргә аннан өйрәндем. Алмаз да, мин дә – милләтебезнең традицияләре сакланган гаиләләрдә үстек. Яшь вакытта ул хакта уйланмаганбыз, хәзер менә аларны саклау һәм балаларга да шул үрнәкне күрсәтүнең никадәр мөһим булуын икебез дә аңлый», – ди Гөлназ.

Нурмиевларның үз гаилә бизнеслары. Эш графиклары никадәр тыгыз булмасын, иҗтимагый эшләргә дә вакыт бүләргә тырышалар. 2018 елдан бирле йөгерү марафонында катнашалар. Ноябрь – аларның гаилә корган айлары. Алмаз, Анур һәм Нурсолтанның да туган көннәре ноябрьдә.

Әле, җитмәсә, 16 ноябрь Самбо көне дә. «Ноябрь – безнең өчен бәйрәмнәр ае», – ди Нурмиевлар. Нинди бәйрәм тәмле ризыксыз булсын инде?!

Алар тәкъдим иткән менә бу аш журнал укучыларыбызга көзге салкыннарны җиңәргә ярдәм итәр дип ышанабыз.



## Кирәк

500 г тавык ите;
2 л су;
300 г арпа ярмасы (перловка);
1 зур суган;
1 зур кишер;
1-2 бәрәңге;
1 л сөт;
20 г атланмай;
берәр чәй кашыгы куркума, зира, кориандр;
тәменчә тоз;
үсемлек мае.



## Эш барышы



■ Суганның кабыгын әрчеп, вак итеп турыйбыз.



■ Тавык итен юып, 2 литр су белән шулпа кайнатырга куябыз. Ит пешкәч, шулпаны зуррак кәстрүлгә сөзәбез.



■ Ярманы юып, ярты сәгатькә кайнар суга салып торабыз. Ул арада ярма бераз бүртеп, йомшарып китә.



■ Кишерне эре угычтан уабыз. Нечкә генә саламлап турарга да мөмкин.



■ Бәрәңгене вак шакмаклап турыйбыз. Эре угычтан да уарга була.



■ Табага үсемлек мае салып, башта суганны, аннары кишерне өстәп, кыздырабыз. Бәрәңге белән арпа ярмасын да шунда кушабыз.



■ Кызган яшелчәләрне сөзгән шулпага салып, яңадан кайнатырга куябыз. Тәменчә тоз өстибез. Арпа ярмасы йомшарганчы пешәргә тиеш.



■ Калын төпле савытта атланмайны эретеп, берәр чәй кашыгы куркума, төелгән кориандр һәм зираны кыздырабыз. Аннары сөтне салып, кайнатып чыгарабыз.



■ Шулпага хуш исле сөтне һәм ваклап туралган итне кушабыз. Тагын бер кат кайнатып чыгарып, шулпаны сүндерәбез. Табынга биргәндә туралган петрушка һәм ачы борыч сибәбез.



Ашларыгыз тәмле, табыннарыгыз мул, еллар имин булсын!

Фото һәм видео: Анна Арахамия

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз »

podpiska.pochta.ru